| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«14» июнь, 2024 ел Олы Кайбыч ав. №268

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләренең урынбасарларының, аудиторларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтада:

-2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлары күләменнән чыгып исәпләнә. Шул ук вакытта авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады 13323 сум тәшкил итә.»;

- 5 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын муниципаль хезмәт вазыйфасына кертү белән бәйле рәвештә акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрне акчалата бүләкләү

күләме элек биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла торган җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда элек биләгән хезмәт хакы кимрәк булган очрактан тыш, вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү;»;

- 11 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата бүләкләүне - вазыйфаи окладларның 41 процентыннан артмаган күләмдә.».

1.2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Нигезләмәсенең 2 нче кушымтасын 1нче кушымтада каралган яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. ««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Нигезләмәсенең 6 нчы кушымтасын 2 нче кушымтада каралганяңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка таратырга).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе,<br>
Кайбыч муниципаль районы<br>
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 2024 елның
14 08 ____________268 номерлы
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Нигезләмәсенә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазыйфа атамасы | акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 35272 |
| Башлык урынбасары | 31745 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 31745 |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 2024 елның
14.06 268 номерлы
карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Нигезләмәсенә 6 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгына, башлыгы урынбасарына, Контроль-хисап палатасы рәисенә, Башкарма комитет җитәкчесенә айлык өстәмә акчалата түләүләр күләме**

| Вазыйфа атамасы | Айлык акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 104678 |
| Башлык урынбасары | 51753 |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 14878 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 31290 |